ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

________29.07.2024_________ **Чистай шәһәре** № ____323_________

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб-белгечләргә торак урынны наемга (арендага) түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 июлендәге 466 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карарын, «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 октябрендәге 615 номерлы Башкарма комитет карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 7 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урынны наемга (арендага) түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 15.07.2022 ел, №466 карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб-белгечләргә торак урынны наемга (арендага) түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә (алга таба Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 бүлектә Гомуми нигезләмәләр:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы һәм Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннарның табиб-белгечнең һәм аның гаилә әгъзаларының милектә булмавы, моңа Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы һәм Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак бинага гомуми өлешле милек хокукындагы өлешнең табиб-белгече гаиләсе әгъзаларының милкендә булу очраклары керми. Шул исәптән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы һәм Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак бинага бер үк вакытта гаилә әгъзасының милек хокукында булган торак бинада һәм Татарстан Республикасы Чистай шәһәре һәм Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан башка торак биналарда өлеше (шул исәптән, гаилә әгъзасына караган торак бинада) булу керми.

1.2 бүлектә торак урынны наем (аренда/субаренда) белән бәйле чыгымнарның табиб-белгечләренә компенсация күләмен исәпләү тәртибе

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-компенсация күләме торак урынны наем шартнамәсе (арендалау/субарендалау) белән билгеләнә, әмма «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» расланган муниципаль программада билгеләнгән 4500 сум күләмендәге максималь әһәмияттән артмаска тиеш.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы П.Б. Емельянов